**Татарстан Республикасы Азнакай районы**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №241-27 «25» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (14.12.2022 №188-20, 18.04.2023 №208-24 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 04 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (14.12.2022 №188-20, 18.04.2023 №208-24 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 43 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;
2) 44 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «программаныраслаган район Башкарма комитеты карары нигезендә» сүзләрен «районның Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль программалар бюджет турындагы карарга агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.»;

3) 45 статьяның 2 пунктында:

түбәндәге эчтәлекле өченче - бишенче абзацлар өстәргә:

«транспорт салымыннан җирле бюджетлар керемнәре (әгәр Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле бюджетларга транспорт салымыннан чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетлар керемнәре;

авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетлар керемнәре;»

өченче абзацны алтынчы абзац дип санарга;

4) 50 статьяның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы Азнакай район Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 45 статьясындагы 2 пунктының дүртенче һәм бишенче абзацлары нигезләмәләре, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеттан башлап, Азнакай муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo. tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин